# СҮЗЛЕК

Шартлы кыскартмалар:

*Ачыл.* – Ачылыш
*Евр.* – Еврейләргә хат
*Көл.* – Паулдан көллесәйлеләргә хат
*1 Көр.* – Паулдан көринтлеләргә беренче хат
*Лүк* – Лүк бәян иткән Яхшы хәбәр
*Марк* – Марк бәян иткән Яхшы хәбәр
*Мат.* – Маттай бәян иткән Яхшы хәбәр
*2 Пет.* – Петердән икенче хат
*Рәс.* – Рәсүлләрнең эшләре
*Рим.* – Паулдан римлыларга хат
*1 Тим.* – Паулдан Тимутегә беренче хат
*2 Тим.* – Паулдан Тимутегә икенче хат
*Яхъя* – Яхъя бәян иткән Яхшы хәбәр
*Яһүд.* – Яһүдтән хат

гр. – грек телендә
*к.* – карагыз
М. т. к. – Мәсих туганга кадәр (Безнең эрага кадәр)
М. т. с. – Мәсих туганнан соң (Безнең эрада)
яһ. – яһүд телендә

Еллар якынча бирелә.

***АДӘМ УЛЫ*** – Арамей телендә бу сүзтезмә «кеше» дигәнне аңлата. Иске Гаһеднең «Данил» китабы, 7:13–14 нче аятьләрдә шушы ук сүз илаһи Затка карата кулланыла. Инҗил китабыннан билгеле булганча, Гайсә Мәсих Үзен Адәм Улы дип атый. Шушы исем белән аталуы Аның бер үк вакытта кеше һәм илаһи зат булуын күрсәтә *(Марк 8:31; Рәс. 7:55–56).*

***АКЛАУ*** – Грек сүзенең туры мәгънәсе: «гаепсез дип белдерү». Инҗилдәге мәгънәсе: Аллаһы Тәгалә кешенең гөнаһларын кичерә, кешене гаепсез дип белдерә һәм кешене Үзе алдында

хак саный. Аллаһы Тәгалә бары тик кешенең Гайсә Мәсихкә иман китерүе аркылы гына аклый *(Рим. 3:28). к.* ***Тәкъвалык, Хаклык***

***АЛЛАҺЫ*** (яһ. *Эл*, *Элоһим*) – Бердәнбер, Кодрәтле, бар нәрсәне Барлыкка китерүче һәм бар нәрсәне хөкем итәчәк бердәнбер Хаким.

***АЛЛАҺЫ БӘРӘНЕ*** – Тәүратта күрсәтелгәнчә, Муса кануны буенча, гөнаһлары кичерелсен өчен, һәр кеше корбан итеп бәрән китерергә тиеш булган. Гайсә Мәсих «Аллаһы Бәрәне» дип атала, чөнки Ул һәр кешенең гөнаһлары өчен Аллаһы китергән корбан Бәрәне *(Яхъя 1:29; Ачыл. 5).*

***АЛЛАҺЫГА ТАБА БОРЫЛУ*** – Кылган гөнаһлар өчен тәүбә итеп, Аллаһыны тыңламаучанлыкны һәм гөнаһлы тормышны калдырып, Аллаһы юлына басу. *к.* ***Тәүбә итү***

***АЛЛАҺЫ ЙОРТЫ*** – Корбан китерү һәм гыйбадәт кылу өчен Аллаһы Үзе күрсәткән үрнәк буенча төзелгән бина.

Аллаһы Йортының корбан китерү урыны урнашкан җиргә руханилар гына керә алганнар. Аллаһы Йортының ишегаллары эченә урнашкан бина ике бүлмәдән: Изге урыннан һәм Иң изге урыннан торган. Иң изге урынга баш рухани гына, елга бер тапкыр, махсус гыйбадәт хезмәте башкару өчен керә алган. Бу бүлмә Изге урыннан зур пәрдә белән бүлеп куелган булган *(Мат. 27:51).*

Гайсә Мәсих алдан күреп әйткәнчә, М. т. с. беренче гасырда Аллаһы Йорты римлылар тарафыннан бөтен килеш җимерелгән.

***АЛЛАҺЫ ПАТШАЛЫГЫ*** – Аллаһының бу дөньяда да, киләчәк дөньяда да кешеләр һәм бөтен нәрсә өстеннән хакимлек итүе, кешеләрнең Аллаһы Тәгаләнең ихтыярына, хакимлегенә буйсынып яшәве. Гайсә Мәсих Аллаһы Патшалыгы турында күп өйрәткән.

***АРАМЕЙ ТЕЛЕ*** – Борынгы яһүд һәм гарәп телләренә кардәш тел. Гайсә Мәсих җирдә яшәгән чорда яһүдләр, нигездә, арамей телендә сөйләшкәннәр.

***АТА*** (Аллаһыга карата) – Гайсә Мәсих Аллаһыны «Ата» дип атый, шуның белән Аллаһының Үз халкына, Үзенә иман итүчеләргә карата булган мөнәсәбәтен – Ата белән балалары арасындагы мөнәсәбәтне ачык итеп күрсәтә. Гайсә Мәсихкә

иман китергән кеше Аллаһы белән шундый мөнәсәбәткә керә һәм шуңа күрә Аллаһыны «Атам» дип атый ала.

***ӘГРИП*** (Әгрип II) – Һируд Әгрип I нең улы (*к.* ***Һируд***). Ул Фалыстын җиренең кайбер өлешләре өстеннән М. т. с. якынча 53–93 нче елларда идарә иткән *(Рәс. 25:13–26).*

***БАБЫЛ*** – Иске Гаһед чорында Бабыл империясе Исраил халкының явыз дошманы булган. Инҗил китабында читләтеп әйтелгәндә «Бабыл» сүзе иблис патшалыгын аңлата.

***БАГАЛ*** – Борынгы Кәнган кешеләре табынган илаһ *(Рим. 11:4).*

***БЕРДӘМЛЕК*** – (гр. *экклесиа*) Бу сүз Инҗилдә ике мәгънәдә кулланыла: 1) Гайсә Мәсихкә иман итүчеләрнең бер урындагы җәмгыяте, җыелышы; 2) җир йөзендә яшәүче барлык мәсихчеләр (Гайсә Мәсихкә ышанучылар).

***БИЛЬЯМ*** – Иске Гаһед чорында яшәгән пәйгамбәр *(Тәүрат, «Саннар» китабы 22–24).* Инҗилдә ул тискәре, гөнаһлы образ буларак күрсәтелә *(2 Пет. 2:15; Яһүд. 11; Ачыл. 2:14).*

***ВАКЫТ ХИСАБЫ*** – Көндезге вакыт, безнең вакыт хисабы буенча, иртәнге сәгать алтыдан башланып, кичке сәгать алтыга кадәр, кичке вакыт – кичке алтыдан төнге уникегә кадәр, төнге вакыт – төнге уникедән иртәнге алтыга кадәр дәвам иткән. Мәсәлән, «беренче сәгать» иртәнге алты белән җиде арасына, «тугызынчы сәгать» көндезге ике белән өч арасына туры килгән.

***ГАЛӘМӘТ*** – Берәр хәлне күрсәтә, исбат итә торган Аллаһы тарафыннан кылынган могҗизалы билге. Аллаһы Тәгалә Мәсих аркылы күп галәмәтләр кылган *(Мат. 12:39–40; Яхъя 6:14).*

***ГАМУРА*** – Үле диңгез буендагы тигезлектә урнашкан биш шәһәрнең икесе Сәдүм һәм Гамура исемнәрен йөрткән. Аллаһы ул ике шәһәрдә яшәүче кешеләрнең гөнаһлары өчен күктән утлы күкерт яңгыры яудырып, Сәдүм һәм Гамура шәһәрләрен юкка чыгарган *(Тәүрат, «Яратылыш» китабы 19).*

***ГАҺЕД*** – Ике як бер-берсе белән төзегән килешү (*к.* ***килешү***). «ИСКЕ ГАҺЕД», «ЯҢА ГАҺЕД» – китап исемнәре. *к. Кереш сүз*

***ГӨНАҺ*** – Белә торып яки белмичә Аллаһы тарафыннан билгеләнгән канун тәртипләрен бозу, Аллаһыны тыңламау һәм Аллаһыга буйсынмау.

***ГРЕК ТЕЛЕ*** – Гайсә Мәсих җирдә яшәгән чорда бөтен Урта җир диңгезе буена урнашкан илләрдә аралашу теле булган. Инҗил китабы грек телендә язылган.

***ГЫЙБАДӘТХАНӘ*** – Гыйбадәт кылу йорты. Яһүдләр торган һәр шәһәрдә гыйбадәтханә булган. Яһүдләрнең гыйбадәтханәләрендә Аллаһы сүзен өйрәткәннәр, Изге язманы укыганнар, дога кылганнар.

***ДАВЫТ*** – Исраилнең икенче патшасы (М. т. к. якынча 1003 нче еллардан башлап). Давыт Исраилне бөек дәүләткә әйләндергән, Иерусалимны дәүләтнең башкаласы иткән. Ул шулай ук оста сугышчы һәм бөек шагыйрь булган, Аллаһыга дан җырлый торган күп кенә мәдхияләрнең авторы буларак та билгеле. Ул иҗат иткән мәдхияләр Зәбур китабының шактый өлешен тәшкил итә.

***ДАН*** – Гомумән әйткәндә, «Аллаһының даны» сүзтезмәсе Аллаһының чиксез хакимлеген һәм мәһабәтлеген аңлата. Изге Китаптан мәгълүм булганча, кайбер очракларда Аллаһының даны исраиллеләргә көчле яктылык, ут йә төтен рәвешендә күренгән. Гайсәнең тормышы, Ул тудырган могҗизалар һәм, бигрәк тә, Аның хачтагы үлеме, үлгәннән соң терелүе – болар барысы да Аллаһы Улы данына дәлил булып тора.

***ДОГА КЫЛУ*** – Аллаһыга сүзләр белән мөрәҗәгать итү, Аллаһы белән сөйләшү. Инҗилдән күренгәнчә, Гайсә Мәсих тә, Гайсәнең шәкертләре булган унике рәсүл дә, калган иман итүчеләр дә Аллаһыга күңел түрләреннән чыккан сүзләр белән мөрәҗәгать иткәннәр һәм Аллаһыдан җавап алганнар.

***ЗӘБУР*** – Иске Гаһеднең бер китабы. Бу китап Аллаһыга багышланган 150 мәдхиядән тора. Яһүдләр бу мәдхияләрне гыйбадәт кылган вакытта җырлаганнар.

***ИБЛИС*** – Явыз рухлар башлыгы. *Иблис* сүзе грек теленнән гарәп теле аша, ә аның синонимы *шайтан* яһүд теленнән килә.

***ИБРАҺИМ*** – М. т. к. 2000 нче елларда яшәгән. Аллаһы Тәгалә Ибраһим белән килешү төзегән. Исраил халкы Ибраһимнан башланып киткән – ул Исраил халкының нәсел башы. Ул Аллаһыга тыңлаучан, тугры булган, Аллаһыга нык ышанган. Шуңа күрә Ибраһимны «иман атасы» дип атыйлар (*Лүк 3:8; Рәс. 7:2–8; Рим. 4; Евр. 11:8–12).*

***ИЗГЕЛӘР, АЛЛАҺЫНЫҢ ИЗГЕ КЕШЕЛӘРЕ*** – Аллаһыныкы, Мәсихнеке булган, иман аша Аның белән якын мөнәсәбәттә торган кешеләр.

***ИЗГЕ ЧАТЫР, ШАҺИТЛЕК ЧАТЫРЫ*** – Аллаһы Йорты төзелгәнче исраиллеләр Аллаһыга Шаһитлек чатырында корбан китергәннәр һәм Аңа табынганнар *(Тәүрат, «Чыгыш» китабы 25:8, 22; Рәс. 7:44; Евр. 13:10).*

***ИЗГЕ РУХ*** – Аллаһының Рухы, шуңа күрә Аңа Аллаһының барлык сыйфатлары хас. Яңа Гаһедтән билгеле булганча, Гайсә Мәсихкә иман китергән кеше Изге Рухны кабул итә.

***ИЗГЕ РУХ БЕЛӘН СУГАРЫЛУ*** – Аллаһының Рухы һәм Аның куәте белән тутырылу. Изге Рух белән сугарылган иман итүче аша Изге Рухның көч-куәте, зирәклеге, сәләтләре, эшләре хәрәкәткә килә ала.

***ИЗГЕ ЯЗМА, ИЗГЕ ЯЗМАЛАР*** – Иске Гаһед язмалары Яңа Гаһедтә шулай дип атала. *к.* ***Иске Гаһед***

***ИЛЛЕНЧЕ КӨН БӘЙРӘМЕ*** – Коткарылу бәйрәменнән соң илленче көнне яһүдләр бөртеклеләрнең уңышын җыеп алуны бәйрәм иткән көн.

***ИЛЬЯС*** – М. т. к. 800 нче елларда яшәгән пәйгамбәр. Исраил патшалыгы белән идарә иткән Ахаб патша һәм аның хатыны Изебел ялган илаһларга табынганга күрә, Ильяс пәйгамбәр аларга Аллаһы сүзен сөйләгән. Ильясның Мәсих килүне әзерләү өчен җиргә кайтачагы турындагы Малаки пәйгамбәр сүзләре яһүдләргә мәгълүм булган *(Марк 9:4; Рим. 11:2–5).*

***ИМАН ИТҮЧЕЛӘР*** – Гайсә Мәсих аша котылуны һәм гөнаһларының кичерелүен кабул итеп, Аллаһы Тәгаләгә ышанучы кешеләр.

***ИРЕМИЯ*** – М. т. к. 600–500 нче елларда яшәгән пәйгамбәр.

***ИСЕМ*** **(ИСЕМЕННӘН, ИСЕМЕ БЕЛӘН, АНЫҢ ИСЕМЕ һ. б.)** – Шәхеснең барлык сыйфатларын күздә тотып, шәхескә карата кулланыла торган сүз. «Исем» дигән сүз шул затның үзен аңлата. Мәсәлән, Гайсә шәкертләре «Гайсә исеме белән/исеменнән» дигән сүзләрне кулланып, авыруларны савыктырганда, Гайсәнең кодрәте хәрәкәт иткән, савыктырган.

***ИСКЕ ГАҺЕД*** – Күп еллар дәверендә (якынча 800–1000 ел), төрле вакытта күп кешеләр тарафыннан язылган китаплар җыентыгы. Ул язмалар – кешеләр язып алган Аллаһы сүзе. *к.* ***Изге язма***

***ИСХАК*** – М. т. к. 1900 нче елларда туган. Ибраһим белән Сараның улы.

***ИШАГЫЙЯ*** – М. т. к. 700 нче елларда Иерусалимда яшәгән пәйгамбәр.

***ЙОЛЫП АЛУ*** – Грек телендәге мәгънәсе: тиеш булган бәяне түләп, ниндидер явызлыктан азат итү. Инҗил буенча, кешене гөнаһ хакимлегеннән азат итәр өчен түләнгән бәя – Гайсә Мәсихнең корбан булып үлүе.

***ЙОСЫФ*** – Ягъкубның унике улының берсе. Абыйлары аны кол итеп Мисырга сатканнар. Фиргавен аны Мисыр өстеннән идарәче итеп билгеләгән *(Тәүрат, «Яратылыш» китабы 37–41).*

***КАЙСАР*** – Рим императорының рәсми исеме.

***КАНУН*** (Муса кануны) – Аллаһының Исраил халкына биргән кануны. «Канун» дигәндә Муса аркылы бирелгән ун әмер, яки Тәүрат китабы, кайвакыт Иске Гаһеднең бөтен китаплары күздә тотыла. Нәсыйхәт һәм кагыйдәләр җыентыгы буларак, канун Аллаһының Үз халкына карата булган теләген, Исраил халкының ничек яшәргә тиешлеген күрсәтә.

***КАНУНЧЫ*** – Муса кануны белгече. Канун текстына үзгәртүләр керттермичә, аны күчереп язуны, өйрәнүне һәм башкаруны күзәтү – аның җаваплылыгында булган. Канунчылар кешеләрне канунга өйрәткәннәр.

***КИЛЕШҮ*** – Килешү төзегәндә һәр як үз өстенә ниндидер бурычлар алып, вәгъдәләр бирә. Изге Китапта Аллаһы кешеләр белән төзегән килешү төп урынны алып тора. Кодрәтле Аллаһы кешелеккә ярдәм кулын суза, Үзе башлап, кешелек белән килешү төзи. Аллаһы кешеләр белән төзегән килешүләрнең иң мөһимнәре – иске һәм яңа килешүләр. Аллаһының Исраил белән Синай тавында Муса аша төзегән килешүен «иске килешү» диләр *(Тәүрат, «Чыгыш» һәм «Канун» китаплары).* Аллаһы белән кешеләр арасында яңа килешү булачагы турында пәйгамбәрләр алдан күреп сөйләгәннәр. Инҗил китапларыннан билгеле булганча, яңа килешү Гайсә Мәсихнең үлеп терелүенә нигезләнгән, Аның каны белән расланган *(1 Көр. 11:25; Евр. 7:22; 8:13).*

***КИЛЕШҮ САНДЫГЫ*** – Агачтан алтын белән йөгертелеп ясалган сандык. Аның эчендә Аллаһының ун әмере язылган таш тakталар сакланган. Сандык Изге чатырның, ә Аллаһы

Йорты төзелгәннән соң, Аллаһы Йортының Иң изге урынында торган *(Евр. 9:4; Ачыл.11:19). к.* ***Аллаһы Йорты***

***КОРБАН КИТЕРҮ*** – Исраиллеләр кылган гөнаһларыннан чистарыну өчен корбан итеп хайван чалганнар, Аллаһыны мактау, Аңа рәхмәтләр әйтү йөзеннән бүләкләр китергәннәр. Мәсәлән, үгез, сарык яки кәҗә, шулай ук күгәрчен һәм он, ипи китергәннәр. Корбан китерү тәртипләре Тәуратта күрсәтелгән. Инҗилдән билгеле булганча, кешелекнең барлык гөнаһларын кичерү өчен җитәрлек булган, Аллаһы Тәгалә Үзе китергән бердәнбер корбан – Гайсә Мәсих.

***КОРБАН КИТЕРҮ УРЫНЫ*** – Корбанга хайваннарны китерү өчен таштан, туфрактан, йә тимердән ясалган калку урын. Муса вакытыннан башлап, Аллаһыга корбан китерү урыны бары тик Изге чатырда, соңыннан Аллаһы Йортында гына булган һәм корбан китерү хезмәтен бары тик руханилар гына башкарырга тиеш булган.

***КОТКАРУЧЫ*** – Аллаһы Гайсә Мәсихне бар халыклар өчен Коткаручы итеп күтәргән *(Рәс. 5:31).* Коткаручы Гайсә Мәсих кешеләрне гөнаһ коллыгыннан, гөнаһ өчен гаепләнүдән һәм хөкем җәзасыннан – мәңгелек һәлакәттән коткара.

***КОТКАРЫЛУ БӘЙРӘМЕ*** (гр. *пасха*) – Исраил халкының бәйрәме. Аллаһы кушуы буенча, алар Мисыр коллыгыннан коткарылуларын бәйрәм иткәннәр.

***КУЛЛАРНЫ КУЮ*** (кемдер өстенә) – Символик хәрәкәт, дини йола. Яңа Гаһедтән билгеле булганча, түбәндәге очракларда кулланылган: 1) фатиха биргәндә *(Мат. 19:13,15)*; 2) берәр рухи хезмәткә багышлаганда *(Рәс. 6:6; 13:3)*; 3) берәүнең Аллаһы тарафыннан ниндидер аерым хезмәткә көч-сәләт кабул итүе өчен дога кылганда *(1 Тим. 4:14; 2 Тим. 1:6)*; 4) берәр кешенең Изге Рухны кабул итүе өчен дога кылганда *(Рәс. 8:17; 19:6);* 5) авыру-зәхмәтләрдән савыктырганда *(Марк 6:5; Лүк 4:40; 13:13, Рәс. 28:8).*

***КҮКЛӘР ПАТШАЛЫГЫ*** *– к.* ***Аллаһы Патшалыгы***

***ЛЕВИ*** – Ягъкуб улларының берсе. Аллаһы әмере буенча, Аллаһы Йортында Леви нәселенең Һарун ыруы гына рухани булып, ә калган ырулар рухани ярдәмчесе булып хезмәт иткәннәр. *к.* ***Рухани***

***ЛЕВИЛЕ*** – Аллаһы Йортында рухани ярдәмчесе булып хезмәт итү өчен сайланган нәселдән, Леви нәселеннән булган кеше.

***ЛУТ*** – Ибраһимның бертуган энесенең улы. Бозыклык белән тулган Сәдүм шәһәрен юкка чыгарганчы, Аллаһы Лутны һәм аның гаиләсен шәһәрдән алып чыгып, коткарган *(Лук 17:28–32).*

***МАЙ СӨРТҮ*** – Ниндидер үзенчәлекле хезмәткә багышлау билгесе итеп, кешенең башына хуш исле майлар катнашмасы сөртә торган булганнар яки агызганнар. Бу йоланы кемне дә булса патша, рухани һәм кайбер очракта пәйгамбәр хезмәтенә багышлаганда кулланганнар. *к.* ***Мәсих***

***МӘҖҮСИ*** – Чын Аллаһыга табынмаучы, потка һ. б. табынучы кеше.

***МӘЛИК-САДЫЙК*** – Шалим патшасы, рухани булган. Ибраһим аңа сугышта тапкан байлыгының уннан бер өлешен тапшырган, һәм Мәлик-Садыйк Ибраһимга фатихасын биргән. Мәлик-Садыйк турында Тәүраттагы «Яратылыш» китабының 14:17–20 дән укырга мөмкин *(Евр. 5:6–10; 6:20; 7:1–17).*

***МӘСИХ*** (гр. *Христос*) – Гайсә титулларының берсе. Бу сүзнең мәгънәсе «май сөртелгән» дигәнне аңлата. Исраилгә патша сайлап куйганда руханилар, Аллаһы кушуы буенча, билгеләнгән кешенең башына хуш исле майлар катнашмасы сөртә торган булганнар. Мәсих Гайсә – дөньяны коткару өчен Аллаһы тарафыннан сайланылган һәм май сөртелгән Зат.

***МӘСИХЧЕ*** – Аллаһыга иман итүче, Гайсә Мәсих аркылы гөнаһларының кичерелүен кабул итеп алган, Аллаһы тарафыннан коткарылган иман итүче кеше, Мәсихнең иярчене.

***МУСА*** – Якынча М. т. к. 1570 нче елларда туган, Исраил халкының иң танылган дини һәм сәяси башлыгы, пәйгамбәр. Ул халыкны Мисыр коллыгыннан алып чыккан. Муса Аллаһыдан килгән канунны халыкка җиткерүче булган.

***НИНӘВИ*** – Борынгы Ашур империясенең башкаласы.

***НУХ*** – Аллаһы Тәгалә дөньяны туфан белән юкка чыгарыр алдыннан Нух, Аллаһы кушуы буенча, зур көймә төзегән һәм туфан кубарыла башлаганчы үзенең гаиләсе белән шул көймәгә кереп һәлакәттән котылып калган *(Мат. 24:36–39).*

***ПӘЙГАМБӘР*** – Аллаһы тарафыннан сайланган, Аллаһыдан кабул иткән сүзләрне кешеләргә җиткерүче, игълан итүче кеше.

***РАББЫ*** (гр. *Куриос*, яһ. *Адонай*) – Яһүд һәм грек телләрендә бу сүз «нәрсәнеңдер яки кемнеңдер хуҗасы» дигән мәгънәне аңлата. Изге Китап язылган чорда хатын-кызлар шушы исем белән үзләренең ирләренә, хезмәтчеләр һәм коллар үзләренең хуҗаларына мөрәҗәгать иткәннәр. Бу сүз белән Аллаһыга мөрәҗәгать иткәндә Аллаһының кешелек өстеннән, бөтен матди һәм рухи дөнья өстеннән хуҗа булуы аерып күрсәтелә. Инҗилдә Раббы исеме Гайсә Мәсих турында еш кулланыла.

***РАББЫНЫҢ КӨНЕ*** – Раббы хөкем белән киләчәк көн. Ул көнне Аллаһы бөтен дөньяны Гайсә Мәсих аркылы хөкем итәчәк. Бу көн «кыямәт көне» дип тә атала.

***РАБИГА*** – Ибраһим улы Исхакның хатыны, Эсау белән Ягъкубның анасы.

***РӘСҮЛ*** (гр. *апостолос*) – «Җибәрелгән кеше» дигән мәгънәдә. Бу сүзнең Инҗилдәге мәгънәсе: Аллаһы тарафыннан сайланып җибәрелгән илче. Гайсә Мәсих аңа вәкаләт биргән. Беренче рәсүлләр – Гайсәнең унике шәкерте.

***РИМ*** – Гайсә Мәсих җирдә яшәгән чорда күп илләрне, шул исәптән Исраил илен яулап алган зур империя. Башкаласы да Рим дип аталган.

***РУХАНИ*** – Аллаһы Йортында хезмәт итүче. Руханиның төп вазифасы – кешеләр алып килгән корбанны Аллаһыга китерү һәм башка дини хезмәтләрне башкару булган. Исраиллеләрдә, Аллаһы кушуы буенча, Һарун ыруы кешеләре генә рухани булып хезмәт иткән.

***САДДУКЕЙ*** – Нигездә руханилардан һәм байлардан торган төркемнең әгъзасы. Саддукейлар яһүд халкының йолаларын тоткан. Фарисейләрдән аермалы буларак, алар үлеп терелүгә ышанмаганнар, Тәүратны, ягъни Мусаның биш китабын гына Аллаһы сүзе итеп таныганнар.

***САРА*** – Ибраһимның хатыны, Исхакның анасы.

***СӘДҮМ*** – *к.* ***Гамура***

***СИНАЙ ТАВЫ*** – Урта җир диңгезеннән көньякта урнашкан Синай ярымутравындагы тау. Аллаһы Тәгалә бу тауда Муса аркылы Исраил халкына Үзенең ун әмерен биргән.

***СӨЛӘЙМАН*** – Давыт улы, Давыттан соң Исраил патшасы (М. т. к. 961–922 нче елларда). Сөләйман патшалык иткән

дәвердә Исраил дәүләте шаулап чәчәк аткан. Иерусалимда иң беренче Аллаһы Йортын Сөләйман төзегән.

***СӨННӘТКӘ УТЫРТУ*** – Аллаһы Тәгалә Ибраһим белән килешү (гаһед) төзегән һәм шул килешүнең билгесе итеп Ибраһимга үзен, йортындагы һәр ир затын һәм киләчәк буыннарда туачак һәр ир баланы сөннәткә утыртырга кушкан *(Тәүрат, «Яратылыш» китабы, 17:9–14). к.* ***Килешү***

***СУГА ЧУМДЫРЫЛУ ЙОЛАСЫ*** – Инҗилдә ике төрле суга чумдырылу турында сүз бара.

Яхъя пәйгамбәр тарафыннан чумдырылу – гөнаһлардан тәүбә итүне, гөнаһ кылмаска карар кылып, үзеңне Аллаһы Тәгаләгә багышлауны аңлаткан. Инҗилнең беренче дүрт китабында шундый чумдырылу турында сүз бара *(Мат. 3:1–6).*

Гайсә үлеп терелгәннән соң суга чумдырылу йоласының мәгънәсе тирәнәйде, киңәйде – Гайсәнең үлеп терелүе кебек, кешенең үзе өчен үлүен һәм, Гайсә өчен яшәргә дип, үледән терелтелүен аңлата башлады. Мондый чумдырылу турында Инҗилдә язылган *(Көл. 2:12).*

***ТӘКЪВАЛЫК*** – Аллаһыга тугрылык, Аңа тулаем бирелеп, Аның сүзе буенча яшәү. *к.* ***Хаклык/хак булу, Аклау***

***ТӘҮБӘ ИТҮ*** – Гөнаһның гөнаһ икәнен аңлап, кешенең үз теләге белән шул гөнаһтан, гөнаһлы тормыштан баш тартуы, кылган гөнаһлары өчен үкенүе һәм бүтән гөнаһ эшләмәскә дигән карар кылуы. *к.* ***Аллаһыга таба борылу***

***ТӘҮРАТ*** (яһ. *Тора*) – Канун дигән мәгънәне аңлата. Иске Гаһеднең беренче биш китабын, ә кайвакыт бөтен Иске Гаһедне шушы сүз белән атыйлар.

***ТӨЧЕ КҮМӘЧ БӘЙРӘМЕ*** – Яһүдләрдә Коткарылу бәйрәменнән соң ук Төче күмәч бәйрәме башлана һәм җиде көн дәвам итә. Бәйрәм көннәрендә камыр ашларыннан бары тик төче камырдан пешерелгәнен генә ашарга ярый. Мисырдан чыккан вакытта камыр куярга вакыт булмаганлыктан, Аллаһы кушуы буенча, юлга ипине төче камырдан пешергәннәр.

***УРАЗА ТОТУ*** – Аллаһыга багышлап күпмедер вакыт яки күпмедер көннәр бөтенләй ризык ашамыйча тору. Ул көнне (көннәрне) Аллаһыдан мәрхәмәт һәм ярдәм сорап дога кылалар *(Мат. 4:2; Лүк 18:12; Рәс. 13:2–3).*

***ФАРИСЕЙ*** – Борынгы яһүдләр арасындагы дини төркем әгъзасы. Фарисейләр Муса канунын һәм кешеләр тарафыннан

гасырлар буена канунга өстәлеп килгән кагыйдәләрне төгәл үтәүне алга сөреп яшәгәннәр.

***ФАТИХАЛАУ/ФАТИХА БИРҮ*** – Инҗилдә шушы мәгънәләргә ия: 1) Аллаһы Тәгаләнең кемгә дә булса мәрхәмәт, берәр төрле игелек күрсәтүе *(Евр. 6:14)*; 2) бер кешенең икенче кеше өчен Аллаһыдан мәрхәмәт, берәр төрле игелек күрсәтүне соравы *(Рим.12:14)*.

***ФӘРЕШТӘ*** – Аллаһыга хезмәт итүче һәм, Аллаһы кушуы буенча, кешеләргә ярдәм итүче рухи зат.

***ФИРГАВЕН*** – Борынгы Мисыр патшасы.

***ХАКЛЫК/ХАК БУЛУ*** (гр. *дикайосуне*) – 1) Аллаһыга карата: Аллаһының һәрвакыт дөрес, гадел, тугры булуы, шулай гамәл кылуы *(Рим. 3:5; 2 Пет. 1:1)*; 2) кешегә карата: кешенең Аллаһы белән дөрес мөнәсәбәттә булуы *(Рим. 3:22; 2 Тим. 4:8)*.

Хаклык/хак булу, тәкъвалык, аклау дигән сүзләрнең тамырлары грек телендә бер үк. *к.* ***Тәкъвалык, Аклау***

***ХАЧ*** – Гайсә яшәгән чорда кешеләрне җәзалап үтерү өчен кулланыла торган җайланма, ул бер-берсенә туры почмаклап кагып куелган ике бүрәнәдән гыйбарәт. Аны шулай ук «тәре» дип тә атыйлар. Хачка кадакланып үлү бик авыр һәм иң оят үлем дип саналган.

***ҺАРУН*** – Мусаның абыйсы. Бары тик ул һәм аның ыруыннан булган кешеләр генә рухани булып хезмәт иткәннәр һәм Исраил халкы алып килгән корбаннарны Аллаһыга китергәннәр.

***ҺИРУД*** – 1) Бөек Һируд: бөтен Фалыстын җире өстеннән М. т. к. 37 нче елдан М. т. с. 4 нче елга кадәр идарә иткән яһүд патшасы. Ул идарә иткән вакытта Гайсә Мәсих туган. 2) Һируд Антипас, Бөек Һирудның улы: Гәлиләя өлкәсенең идарәчесе М. т. к. 4 нче елдан М. т. с. 39 нчы елга кадәр. 3) Һируд Әгрип I, Бөек Һирудның оныгы. Ул Фалыстын җире өстеннән М. т. с. 41–44 нче елларда идарә иткән, мәсихчеләрне каты эзәрлекләгән *(Рәс. 12:1–5)*. *к.* ***Әгрип***

***ҺУССӨП*** – Яһүдләрнең дини йолаларында кулланыла торган үсемлек. Руханилар аның ботагын йә яфрагын сыеклыкка (мәсәлән, корбан малы канына) манып, кеше яки әйберне Аллаһы каршында пакь итү өчен шуның өстенә сипкәннәр *(Яхъя 19:29; Евр. 9:19)*.

***ШАЙТАН*** – *к.* ***Иблис***

***ШАМУИЛ*** – Исраилнең соңгы бөек хакиме (М. т. к. 1130 нче еллар). Шамуил пәйгамбәрдән соң Исраилдә патшалар хакимлек итә башлый. Шаулны һәм Давытны патшалыкка Шамуил майлаган.

***ШИМБӘ КӨН*** – Яһүдләрнең Аллаһыга багышланган ял итү көне. Бу көнне эш эшләү катгый тыелган.

***ЭЛИША*** – М. т. к. 800 нче елларда яшәгән, Ильяс пәйгамбәргә ярдәм иткән һәм аның урынына пәйгамбәр хезмәтен башкарган Аллаһы пәйгамбәре *(Лук 4:27).*

***ЮГАРЫ КИҢӘШМӘ*** – Яһүдләрнең хөкем шурасы. Ул җитмеш кешедән: руханилардан, канунчылардан һәм башка мөһим кешеләрдән торган. Киңәшмәдә күбрәк дини мәсьәләләр каралган, шулай ук бу шура римлылар алдында яһүд халкының вәкиле булып та торган.

***ЮНЫС*** – Аллаһы пәйгамбәре *(Иске Гаһед, «Юныс» китабы; Мат. 12:39–41).*

***ЯВЫЗ РУХ, ШАКШЫ РУХ*** – Шайтанга хезмәт итүче, аның ихтыярын башкаручы һәм аның хакимлеге астында торучы рухи зат (җен).

***ЯГЪКУБ*** – Исхакның улы, аның икенче исеме «Исраил».

***ЯХШЫ ХӘБӘР*** (гр. *эуаггелион*) – Аллаһы Тәгалә Исраил халкына биргән вәгъдәләрен Гайсә Мәсихтә тулысынча үтәгән; барлык кешеләр өчен Аның аша котылу юлы ачылган – бу бар кеше өчен Аллаһыдан килгән Яхшы хәбәр *(Мат. 4:23; Рим. 1:2–4).*

***ЯҺҮД*** – Ягъкуб улы, унике ыруг башлыгының берсе. Гайсә Мәсих Яһүд ыруыннан булган.